СОВЕТ БАВЛИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАУЛЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

13. 12. 2018 Баулы шәһәре № 181

Судларның, арбитраж судларның Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы һәм аның составына керә торган җирлекләрнең җирле үзидарә органнары һәм аларның вазыйфаи затларының хокук актларын номатив булмаган дип, карарларын һәм гамәлләрен (гамәл кылмауны) законсыз дип тану турында законлы көченә кергән карарлары нәтиҗәләре буенча хокук куллану практикасы мәсьәләләрен карау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендә кабул ителгән 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясы 1,4 частьләре, 15 статьясы 1нче часте, «Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендә кабул ителгән 273-ФЗ номерлы Федераль законның 6нчы статьясындагы 2.1 пункты нигезендә карар иттем:

1. Судларның, арбитраж судларның Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы һәм аның составына керә торган җирлекләрнең җирле үзидарә органнары һәм аларның вазыйфаи затларының хокук актларын номатив булмаган дип, карарларын һәм гамәлләрен (гамәл кылмауны) законсыз дип тану турында законлы көченә кергән карарлары нәтиҗәләре буенча хокук куллану практикасы мәсьәләләрен карау тәртибен расларга (1нче кушымта).

2. Судларның, арбитраж судларның Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы һәм аның составына керә торган җирлекләрнең җирле үзидарә органнары һәм аларның вазыйфаи затларының хокук актларын номатив булмаган дип, карарларын һәм гамәлләрен (гамәл кылмауны) законсыз дип тану

турында законлы көченә кергән карарлары нәтиҗәләре буенча хокук куллану практикасы мәсьәләләрен карау мәсьәләләрен карау буенча эшче төркем булдырырга һәм аның составын расларга (2нче кушымта).

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Баулы муниципаль районы Советы җирле үзидарә, законлылык, хокук тәртибе һәм депутатлар этикасы буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Баулы муниципаль районы Башлыгы,
район Советы рәисе                                    Р.Х. Гатиятуллин

Татарстан Республикасы Баулы муниципаль
районы 2018 елның «13» декабрь
кабул ителгән 181 санлы
карарына 1нче кушымта

Судларның, арбитраж судларның Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы һәм аның составына керә торган җирлекләрнең җирле үзидарә органнары һәм аларның вазыйфаи затларының хокук актларын номатив булмаган дип, карарларын һәм гамәлләрен (гамәл кылмауны) законсыз дип тану турында законлы көченә кергән карарлары нәтиҗәләре буенча хокук куллану практикасы мәсьәләләрен карау тәртибе

## I. Общие положения

1.1. Әлеге Тәртип Судларның, арбитраж судларның Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы һәм аның составына керә торган җирлекләрнең җирле үзидарә органнары һәм аларның вазыйфаи затларының хокук актларын номатив булмаган дип, карарларын һәм гамәлләрен (гамәл кылмауны) законсыз дип тану турында законлы көченә кергән карарлары нәтиҗәләре буенча хокук куллану практикасы мәсьәләләрен карау (алда – Тәртип, хокук куллану практикасы мәсьәләләре) процедурасын билгели, шулай ук судларның, арбитраж судларның Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы һәм аның составына керә торган җирлекләрнең җирле үзидарә органнары һәм аларның вазыйфаи затларының хокук актларын номатив булмаган дип, карарларын һәм гамәлләрен (гамәл кылмауны) законсыз дип тану турында законлы көченә кергән карарлары нәтиҗәләре буенча хокук куллану практикасы мәсьәләләрен карау буенча эшче төркемне (алда – эшче төркем, суд карарлары) формалаштыру, эшче төркемнең утырышлары һәм ул утырышларның нәтиҗәләрен рәсмиләштерү тәртибе мәсьәләләрен җайга сала.

## II. Эшче төркемне формалаштыру һәм аның эше тәртибе

2.1. Эшче төркем рәис, рәис урынбасары, секретарь һәм эшче төркем

әгъзалары составында кимендә 7 кешедән тора. Эшче төркем составына Татарстан Республикасының Баулы муниципаль районы җирле үзидарә органнарының коррупцион һәм башка хокук бозуларны профилактикалау эше өчен җаваплы зат кертелә.

Эшче төркем составы Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Советы карары белән раслана.

2.2. Эшче төркемнең эше хисап кварталыннан соң килүче айның 10 көненә кадәр үткәрелә торган утырышларда, хисап кварталында суд карарлары турында мәгълүмат кергән очракта гамәлгә ашырыла.

Эшче төркем утырышына чакырылалар:

карала торган мәсьәләләр буенча аңлатмалар бирү өчен, суд тарафыннан гамәлдә түгел дип танылган акт проектын эшләүдә катнашкан Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы җирле үзидарә органнары җитәкчеләре һәм структур бүлекчәләре хезмәткәрләре (алда – башка хезмәткәрләр);

акт, карар, гамәлләр (гамәл кылмау) белән хокуклары бозылган затлар яки аларның вәкилләре (алга таба - башка затлар);

җәмәгать оешмалары, Баулы шәһәр прокуратурасы вәкиле (вәкилләре).

2.3. Суд карарлары турында мәгълүмат, әлеге карарларның күчермәләрен кушып, Баулы муниципаль районы һәм анң составына керүче авыл җирлекләре җирле үзидарә органнары тарафыннан хисап кварталыннан соң килүче айның 5 числосыннан да соңга калмыйча эшче төркем рәисенә квартал саен җибәрелә.

Мәгълүмат түбәндәгеләрне үз эченә алырга тиеш:

- норматив булмаган хокукый актларны чыгару, Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы (аның составына керүче авыл җирлеге) җирле үзидарә органнарының һәм аның вазыйфаи затларының суд тарафыннан гамәлдә түгел (законсыз) дип танылган карарларын кабул итү һәм гамәлләр кылу (гамәл кылмау) нигезләре турында;

- норматив булмаган хокукый актларны, Баулы муниципаль районы (аның составына керүче авыл җирлеге) җирле үзидарә органнарының һәм аның

вазыйфаи затларының законсыз карарларын һәм гамәлләрен (гамәл кылмауларын) гамәлдә түгел дип тану нигезләре;

- башка хезмәткәрләрнең хокук куллану практикасы мәсьәләләрен карауда катнашуы турында.

Чыгарылган суд карарлары турында мәгълүмат һәм карарлар күчермәләре белән бергә норматив булмаган хокукый актны кабул иткән яки әзерләгән вазыйфаи затның (хезмәткәрнең) эш язмасы җибәрелә.

2.4. Эшче төркем рәисе хисап кварталыннан соң килүче айның 10 числосына кадәр эшче төркем утырышын үткәрү датасын һәм утырышка башка хезмәткәрләрне һәм башка затларны чакыру кирәк булу-булмавын билгели.

2.5. Эшче төркем секретаре эшче төркем әгъзаларына һәм утырышка чакырылган башка хезмәткәрләргә һәм башка затларга эшче төркем утырышын үткәрү датасы, урыны һәм вакыты турында хәбәр итә.

Суд тарафыннан гамәлдә түгел (законсыз) дип танылган норматив булмаган хокукый акт чыгаруда катнашкан, гамәлләр кылган (гамәл кылмаган) эшче төркем әгъзалары эшче төркем утырышына чакырылмыйлар.

2.6. Эшче төркем утырышы, анда эшче төркем составының яртысыннан артыгы катнашса, хокуклы булып тора. Утырыш рәис тарафыннан, ә аның булмаганда - эшче төркем рәисе урынбасары тарафыннан үткәрелә.

2.7. Хокук куллану практикасы мәсьәләләрен карау барышында эшче төркем:

суд карарларын, шул исәптән норматив булмаган хокукый актны, Баулы муниципаль районы (аның составына керә торган авыл җирлеге) җирле үзидарә органнарының һәм аның вазыйфаи затларының законсыз карарларын һәм гамәлләрен (гамәл кылмауны) гамәлдә түгел дип тану нигезләрен анализлый;

ачыклый:

суд тарафыннан гамәлдә түгел дип танылган норматив булмаган хокукый актны бастыру, карар кабул итү һәм гамәлләр кылу (гамәл кылмау) мотивларын һәм шартларын;

норматив булмаган хокукый акт проектларын әзерләүдә катнашкан

затларның гамәлләрендә, суд тарафыннан гамәлдә түгел (законсыз) дип танылган гамәлләр кылуында (гамәл кылмау) коррупциячел күренешләр булу-булмауны, шул исәптән:

шулай ук суд тарафыннан гамәлдә түгел дип танылган проектны, актны, гамәлләр кылу (гамәл кылмау) һәм карарларны булдыруда, шулай ук килештерүдә катнашкан затларның шәхси кызыксынулары (мәнфәгатьләр каршылыгы ситуациясе) булу-булмауны;

мондый затлар тарафыннан акт чыгару, карар кабул итү, гамәлләр кылуда (гамәл кылмауда) кызыксынган затларның эш барышына коррупциячел тыкшыну очраклары, башка явыз ниятле гамәлләре очраклары турында хәбәр итмәвен раслаучы фактларны;

законнар җыелмасына туры килми торган хокукый актларны бастырып чыгаруны, карарлар кабул итүне һәм гамәлләр кылуны (гамәл кылмауны), шулай ук коррупцион күренешләрне булдырмауга юнәлтелгән чаралар турында тәкъдимнәр эшләп чыгара.

2.8. Югарыда күрсәтелгән мәсьәләләрне карау нәтиҗәләре буенча эшче төркем коррупциячел күренеш билгеләре булу (булмау) турында Карар кабул итә, шулай ук законнарга каршы килә торган норматив булмаган хокукый актлар кабул итүне, гамәлләр кылуны (гамәл кылмау) кисәтүгә юнәлдерелгән тәкъдимнәр булдыра.

2.9. Әлеге Тәртипнең 2.7, 2.8 пунктларында күрсәтелгән мәсьәләләр буенча эшче төркем карары ачык тавыш бирү юлы белән утырышта катнашучыларның күпчелек тавышы белән кабул ителә. Тавышларның тигезлеге очрагында утырышта рәислек итүче тавышы хәлиткеч булып тора.

2.10. Утырыш нәтиҗәләре буенча секретарь һәм рәислек итүче кул куя торган беркетмә төзелә. Беркетмәдә күрсәтелә:

утырышны үткәрү датасы, вакыты һәм урыны;

утырышта катнашкан эшче төркем әгъзалары һәм башка катнашучылар;

утырышта чыгыш ясаучыларның фамилиясе, исеме, атасының исеме һәм чыгышларның төп тезислары, тәкъдимнәр;

тавыш бирү нәтиҗәләре;

кабул ителгән карар.

Беркетмәгә суд карарлары, суд тарафыннан гамәлдә түгел дип танылган норматив булмаган акт күчермәләре, шулай ук эшче төркемнең карау предметы булган башка материаллар теркәлә.

Утырыш беркетмәсе, шулай ук суд тарафыннан гамәлдә түгел дип танылган норматив булмаган акт, суд карары Баулы муниципаль районының рәсми сайтында «Коррупциягә каршы көрәш» бүлегендә урнаштырылырга тиеш.

2.11. Эшче төркем рәисе утырыш уздырылган көннән алып 3 көннән дә соңга калмыйча, тиешле карарлар кабул итү өчен, Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы (аның составына керүче авыл җирлеге) җирле үзидарә органы җитәкчесенә беркетмә җибәрә.

2.12. Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы (аның сотавына керә торган авыл җирлеге) җирле үзидарә органнарының һәм аның вазыйфаи затларының карарларында һәм гамәлләрендә (гамәл кылмавында) коррупция билгеләре ачыкланган очракта, эшче төркем рәисе беркетмәне һәм эшче төркемнең карау предметы булган башка материалларны, коррупцияне профилактикалау һәм булдырмау буенча чаралар эшләү өчен, Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт тәртибенә таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу буенча комиссиясенә җибәрә.

Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы 2018 елның «13» декабрь кабул ителгән 181 санлы карарына 2нче кушымта

Судларның, арбитраж судларның Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы һәм аның составына керә торган җирлекләрнең җирле үзидарә органнары һәм аларның вазыйфаи затларының хокук актларын номатив булмаган дип, карарларын һәм гамәлләрен (гамәл кылмауны) законсыз дип тану турында законлы көченә кергән карарлары нәтиҗәләре буенча хокук куллану практикасы мәсьәләләрен карау буенча эшче төркем

СОСТАВЫ

Баулы муниципаль районы башлыгы урынбасары, эшче төркем рәисе;

Баулы муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе, эшче төркем рәисе урынбасары;

Баулы муниципаль районы башкарма комитеты юридик бүлеге начальнигы, эшче төркем секретаре;

Төркем әгъзалары:

Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе;

Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районының «Милек һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы» МКУ җитәкчесе;

Баулы муниципаль районы Финанс-бюджет палатасы җитәкчесе;

Баулы муниципаль районы башлыгының коррупциягә каршы көрәш мәсьәләләре буенча ярдәмчесе;

Баулы муниципаль районы Башкарма комитеты эшләре белән идарә итүче.